# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статью 2 Закона Республики Татарстан «Об установлении налоговой ставки по налогу на прибыль организаций для организаций – участников специальных инвестиционных контрактов»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
14 февраля 2019 года

**Статья 1**

Внести в статью 2 Закона Республики Татарстан от 2 декабря 2017 года № 87-ЗРТ «Об установлении налоговой ставки по налогу на прибыль организаций для организаций – участников специальных инвестиционных контрактов» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 94 (часть I) следующие изменения:

1) часть 2 изложить в следующей редакции:
«2. Для организаций – участников специальных инвестиционных контрактов, являющихся производителями грузовых автотранспортных средств, начиная с налогового периода, в котором в соответствии с данными налогового учета была получена первая прибыль от реализации товаров, произведенных в результате реализации инвестиционного проекта, предусмотренного специальным инвестиционным контрактом, и до окончания срока действия специального инвестиционного контракта, но не позднее 2025 года включительно, налоговая ставка по налогу на прибыль организаций, подлежащему зачислению в бюджет Республики Татарстан, устанавливается в размере 0 процентов.»;

2) в части 4 слова «в течение десяти последовательных налоговых периодов» исключить, слова «но не позднее окончания срока действия специального инвестиционного контракта» заменить словами «до окончания срока действия специального инвестиционного контракта, но не позднее 1 января 2023 года».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении одного месяца со дня его официального опубликования, но не ранее первого числа очередного налогового периода по налогу на прибыль организаций.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
01 марта 2019 года
№ 19-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Махсус инвестиция контрактларында катнашучы йөк автотранспорт чараларын җитештерүче оешмалар өчен махсус инвестиция контрактында каралган инвестиция проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җитештерелгән товарларны реализацияләүдән салым исәп-хисабы буенча беренче табыш алынган салым чорыннан башлап һәм махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы тәмамланганчы, ләкин 2025 елдан (бу елны да кертеп) соңрак түгел, Татарстан Республикасы бюджетына кертелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы 0 процент күләмендә билгеләнә.»;

2) 4 өлештә «алдагы ун салым чоры дәвамында» сүзләрен төшереп калдырырга, «ләкин махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң түгел» сүзләрен «махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы тәмамланганчы, ләкин 2023 елның 1 гыйнварыннан соңрак түгел» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай узгач, әмма оешмалар табышына салым буенча чираттагы салым чорының беренче числосыннан да иртәрәк түгел, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 19-ТРЗ